КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 март г.Казань № 261

Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибен раслау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 23 март, 261 нче
карары белән расланды

# Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеген (алга таба – дәүләт күзәтчелеге) оештыру һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

2. Дәүләт күзәтчелеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезләмәләре кулланыла.

3. Дәүләт күзәтчелеге предметы:

а) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – 68-ФЗ номерлы Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше;

б) җирле үзидарә органнары хокукый актларының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге законнар таләпләренә һәм муниципаль берәмлекләр уставларына туры килүе.

4. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы – Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган).

5. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар (алга таба – вазыйфаи затлар):

а) Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрының беренче урынбасары (халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге мәсьәләләрен алып баручы) (алга таба – министрның беренче урынбасары);

б) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы;

в) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары.

6. Тикшерүләр үткәрү турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар:

а) Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (алга таба – министр);

б) министрның беренче урынбасары.

7. Дәүләт күзәтчелеге кысаларында тикшерүләр үткәргәндә җирле үзидарә органнарының 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган эшчәнлеген характерлый торган документлар һәм материаллар тикшерелә, шул исәптән:

а) гадәттән тыш хәлләр салган зыяннарны кисәтүдә һәм бетерүдә катнашу;

б) халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

в) һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм (яки) һәлакәттән коткару формированиеләрен булдыру, карап тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру.

8. Вәкаләтле орган дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган документларның формаларын расларга хокуклы.

## II. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру

9. Дәүләт күзәтчелеге түбәндәге тикшерүләр төрләрен үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла:

а) документлар тикшерү;

б) күчмә тикшерү.

10. Тикшерүләр план нигезендә һәм планнан тыш үткәрелә.

11. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлегенә планлы тикшерүләр 131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясындагы $2^3$ – $2^5$ өлешләре нигезендә тикшерүләр үткәрүнең еллык планы нигезендә уздырыла.

12. Планлы тикшерүләр ике елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

13. Җирле үзидарә органнарын һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын планнан тыш тикшерү өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) министрның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янауга, шулай ук гражданнарның хокукларын массакүләм бозуга китерә торган бозу фактлары турында гражданнар, юридик затлар мөрәҗәгатьләре һәм дәүләт органнарыннан алынган мәгълүмат нигезендә кабул ителә торган карары;

б) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында, шулай ук ачыкланган бозуларны бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту максатларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре, Россия Федерациясе Генераль прокуроры, Татарстан Республикасы прокуроры таләпләре.

14. Әлеге Тәртипнең 13 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча тикшерүләр Татарстан Республикасы прокуратурасы белән килештереп уздырыла.

15. Тикшерү үткәрү турындагы карарда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) вәкаләтле органның исеме;

б) тикшерү төре;

в) җирле үзидарә органының исеме:

г) җирле үзидарә органының урнашу урыны;

д) тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булган очракта), вазыйфалары;

е) дәүләт күзәтчелеге төре;

ж) тикшерү максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү срогы (башлану һәм тәмамлану датасы);

з) тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре;

и) тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр, шул исәптән тикшерү кәгазе реквизитлары (контроль сораулар исемлеге), әгәр дә план буенча тикшерү үткәргәндә аны куллану мәҗбүри булса;

к) тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле контроль чараларын үткәрү сроклары һәм исемлеге;

л) дәүләт күзәтчелеге тәртибен билгели торган норматив хокукый актның исеме, номеры һәм кабул итү датасы;

м) тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен җирле үзидарә органы тарафыннан бирелергә тиешле документлар исемлеге.

16. Җирле үзидарә органына, тикшерү үткәрелә башлаган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта хаты һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ итеп яки башка уңайлы ысул белән министр карарының күчермәсен җибәреп, план буенча яки планнан тыш тикшерү үткәрү турында хәбәр ителә.

17. Документар тикшерү барышында түбәндәге гамәлләр башкарылырга мөмкин:

а) документларны сорап алу;

б) язма аңлатмалар алу.

18. Күчмә тикшерү үткәргәндә түбәндәге гамәлләр башкарыла:

а) сораштыру;

б) язма аңлатмалар алу;

в) документларны сорап алу.

19. Күчмә тикшерүне үткәрү срогы 10 эш көненнән артып китә алмый.

20. Документларны сорап алганда, алар вәкаләтле органга электрон документ рәвешендә (вәкаләтле орган тарафыннан документларны кәгазьдә тапшыру кирәклеген билгеләгән очраклардан тыш) җибәрелә.

Кәгазьдәге документлар төп нөсхәдә яки таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла.

Тикшерү барышында сорала торган документлар аларны тапшыру турындагы таләптә күрсәтелгән срокта тапшырылырга тиеш.

Тикшерү тәмамланганнан соң, документларның төп нөсхәләре контрольдә тотылучы затка кире кайтарыла.

21. Сораштыру үткәрү барышында аның нәтиҗәләре бәян ителгән белешмә-

ләренең дөреслеген раслаган сораштырылучы зат тарафыннан имза куела торган сораштыру беркетмәсендә, шулай ук, әгәр алынган мәгълүматлар тикшерү өчен әһәмияткә ия булса, тикшерү актында теркәлә.

## III. Тикшерү нәтиҗәләре

22. Тикшерү нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә тикшерү акты төзелә. Тикшерү актына күчмә тикшерү кысаларында алынган язма аңлатмалар, сораштыру нәтиҗәләре, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.

23. Вазыйфаи затлар тарафыннан бозулар ачыкланган очракта, түбәндәге чаралар кабул ителә:

а) ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирү;

б) ачыкланган бозуларга юл куйган затларны Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тарту.

24. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә кәгазьдә рәсмиләштерелә һәм анда түбәндәгеләр бирелә:

а) тикшерү үткәрү турындагы карарга кагылышлы белешмәләр;

б) ачыкланган бозулар турында белешмәләр;

в) ачыкланган бозуларны бетерү турында таләп;

г) ачыкланган бозуларны бетерү сроклары;

д) җирле үзидарә органының җитәкчесе яки вәкаләтле вәкиле күрсәтмәләре белән танышу яки танышудан баш тарту турында, аларның имзалары булу турында яки имза куюдан баш тарту турында белешмәләр.

## IV. Вәкаләтле органның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү

25. Вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

26. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять җирле үзидарә органы һәм (яки) җирле үзидарә органының вазыйфаи заты үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән 30 календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

27. Вәкаләтле орган күрсәтмәсенә карата шикаять җирле үзидарә органы тарафыннан ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә алган көннән 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.